| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ<br>Старосляковского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Иске Эсләк авыл җирлеге<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

09.10.2023 Иске Эсләк авылы № 39-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлегенең генераль планын әзерләү кирәклеге булмау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясындагы 6 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге территориясендә җирлек территориясен куллануны үзгәртү күздә тотылмавына бәйле, социаль-икътисадый үсешнең расланган программасы булмау,Татарстан Республикасын һәм Әгерҗе муниципаль районын территориаль планлаштыру схемаларында федераль, региональ һәм җирле әһәмияттәге объектлар урнаштыру каралмаганга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлегенең генераль планын эшләүдә ихтыяҗ булмавын 2023 елның «30» декабренә кадәр танырга.
2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның «1» гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы порталы составында веб-адрес буенча урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы
Совет рәисе Д.М.Әхмәтов